| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ КУРНАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ КӨРНӘЛЕАВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

с. Сухие Курнали

06.02.2018 № 71

**Об отчете главы**
**Курналинского**
**сельского поселения**
**Алексеевского муниципального района**
**о работе за 2017 год и о задачах на 2018 год**

Заслушав и обсудив отчет главы Курналинского сельского поселения за 2017 год и задачах на 2018 год, Совет Курналинского сельского поселения отмечает, что деятельность Совета Курналинского поселения в прошедшем году была направлена на развитие экономики, социальной инфраструктуры, решение социальных проблем жителей поселения.

Исходя из вышеизложенного,

**Совет Курналинского сельского поселения р е ш и л:**

1. Отчет о работе главы Курналинского сельского поселения за 2017 год утвердить.

2.Рекомендовать Совету и Исполнительному комитету сельского поселения определить основными задачами на 2018 год:

- замена и ввод в действие водонапорной башни в с. Сухие Курнали, ул.Хади Такташ, 1 шт ;
- выполнение работ по строительству и реконструкции сети уличного освещения в с. Сухие Курнали, ул.Школьная - 1 шт, ул.Западная - 4 шт, ул.Фарида Шайдуллина - 1 шт, ул Набережная -2 шт, ул. Татарстан - 5шт, ул Хабибуллы Хайруллина- 3шт.
- закончить ремонт дороги по ул.Хабибуллы Хайруллина;
- организовать сбор твердых бытовых отходов.

3. Разместить настоящее решение на «Официальном портале правовой информации Республики Татарстан» в информационной-телекоммуникационной сети «Интернет», на сайте поселения на Портале муниципальных образований Республики Татарстан и обнародовать на специально оборудованных информационных стендах.

4. Контроль за исполнением настоящего решения оставляю за собой.

**Глава Курналинского**
**сельского поселения** **Х.А.Медведев**

Приложение к решению
Совета Курналинского
сельского поселения
№ 71 от 06.02.2018

Хөрмәтле депутатлар, авылдашлар, кунаклар!

Көрнәле авыл жирлегенә бер авыл – Коры Көрнәле керә, авылда фельдшер-акушерлык пункты, китапханә, авыл мәдәният йорты, мәчет, 2 шәхси кибет, 2 гаилә фермасы бар. Почта бүлеге хәзер Ромоданда, бездә почтальон гына эшли.

2 кибет көнкүреш товарлары белән тәэмин итеп торалар, бу Ахметов И.И. һәм Мусин М.Х. Мәдәният йортында төрле темаларга карата бәйрәмнәр уздырыла, мәчеттә теләүчеләр өчен укулар оештырылган.

Кеше туа -исем кушыла, өйләнешүчеләргә - никах укыла, кеше үлә- женаза намазы укылып күмелә.

Демографик хәл буенча - авылда 335 кеше яши.

Эшкә яраклы барлыгы 110 кеше, 9 кеше НП Алексеевскоеда эшли, 11 кеше бюджет өлкәсендә, 7 кеше беркайда да эшләми. 2017 елда 3 бала туды, 5 кеше вафат булды, 2 никах укылды. Авыл жирлегенә 151 баш мөгезле эре терлек, шуларнын 70-е сыер. Сарык- кәҗә - 30 баш, атлар - 5, бал кортлары -35 оя, тракторлар 13, автомобиль 54, мотоблоклар 17 шт, сөт сату 2017 елда -1445 центнер, ит (барлык төредә) сату 275 ц, суммасы 8203000 сум, авыл хужалыгы кредитларын 2017 елда алучылар булмады.

2017 елда сыерларга һәм кәҗәләргә хөкүмәт биргән субсидиягә бодай арпа таратылды, жир пайлары өчен НП Алексеевское бер пайга 5950 сум акча түләде, КФХ Сунеев бер пайга 3 тюк печән, 3 ц бодай бирде.

2017 елгы бюджет хакында

| | план (тыс.руб) | факт(тыс.руб) |
|---|---|---|
| жир | 271,037 | 336,558 |
| милек | 23 | 31,164 |
| дәүләт пошлинасы | 2 | 2 |
| керемгә салым | 12,662 | 12,662 |

Безнең бюджет зур түгел, «Чиста су», үзара салым, авыл урамнарын яктырту программаларында катнашабыз, 2017 елда бездә башня белән скважина ясалды, аларның тирәсе профнастил белән тотып алынды, бу эш программа тәртибенә кертелгән, мәйданы - 110 метрга га 60 метр, 2018 елда аны су челтәренә тоташтырырга кирәк. Күргәнегезчә, дәүләт тарафынннан су челтәрләренә зур игътибар бирелә. 2015 елда 1500 метр су челтәре, янгын вакытында куллана торган 4 гидрант һәм менә 2017 елда 50 куб су сыешлы башня, боларның барысы 5 000 000 сумга якын акча тотылды. Суга килгәндә, хәзер Алексеевск водоканал оешмасы айлык түләнгән акчаның 30 процентын гына электр энергиясенә түли, әйтик безнен авылдан аена 10000 сум җыелды икән, электр энергиясенә 3000 сум

түли, электр энергиясе артык янган очракта җирле үзидарә чыгымнарны капларга тиеш. Бездә суга түләмәүчеләр бар, алар белән эш алып барабыз. Әйтеп узам, су хисаплагычлары күп гаиләдә куелган. 3 гаиләдә генә хисаплагычлар юк, алар норматив буенча тули. Безнең авылда уртача 11000 сум акча түләнә суга, бер кешегә 35 сум чыга аена, бу бик аз, күрше Левашово авылында 54 сум уртача, аларда йорт хайваннарыда безнекеннән күпкә аз. Бу нәрсәне аңлата, безнен авыл суны шундый экономно тотамы, әллә суга башка юллар бармы, моны ачыкларга кирәк. 2017 елда Алексеевскводоканал хезмәткәрләре тикшереп йөрделәр, хисаплагычсызгына су алучылар элэгүчеләр булды, штрафлары белән тутырып алсак, бөтен чыгымнары белән 38000 сумга төшә, шуның өчен азрак андый кешеләрне белсәгез, кисәтегез, туктатсыннар, барыбер беленәчәк. 2017 елда уртача 64000 сумлык су урланган, бу әле фермада, башка җирләрдән аккан суларны санамыйча. Бөтенесен санап була, суга түләүне тәртипкә салырга кирәк.

Үзарасалым 2016 елда 1 плюс 4 - 71500 сум халыктан җыелды, дәүләт бирде 286000 сум, гомуми акча булды - 357500сум. Акча зират тирәсен карарга каралган иде, зират тирәсе буялды, бу аукцион аша эшләнде. 2017 елда 40000 акча җыелды.

Хайруллин урамындагы юлнын сыйфаты бик начар булды. Бу алдагы салым вакытындагы эшне әйтәм, аны эшләүче организация ООО "РАФ", ул аны 2018 елда сыйфатлы итеп ясап бетерергә тиеш, кирпеч ватыкларын ташып куйды инде, тагын таш китереп ясап бетерер дип ышанасы килә.

Урам утлары буенча проблемалар күп, 2018 елда безнең авыл республика программасына кертелде, 300 метр 5 нче провод ясала, бу Көнбатыш, Мәктәп, Яр буе урамнарына. Калган урамнарда безнең 5 нче электр чыбыгы бар, шулай ук башка урамнарга да лампочкалар кирәк, боларның барысында март аенда куярга ниятлибез, 2018 елда үзара салым акчасының бер өлеше урамнарны яктыртуга каралган, 2017 елның 19 ноябрендә узган референдум өчен 24500 сум гына акча җыелды, 100000 сум җыеласы урынына.

Тагын бер мәсьәлә, безнең авылда чүп-чарны кеше күрмәгәндә, кем кая тели шунда ташлый, бу болай дәвам итәргә тиеш түгел. Быел безгә чүп-чар җыя торган оешма килергә тели. "Экосервис" район үзәгендә һәм башка авылларда да чүп җыя, бу эш түләүле, бер кешегә 50 сум аена. Чүп-чар ташлый торган урыннар бетерелә. Һәрберебездә чүп-чар җыела, аны саклап торалмыйбыз гомер буена, бу эшне ничек итеп оештыру турында сезнең белән хәзер сөйләшербез. Контейнерлар куяргамы, яки өй саен сөт җыйган кебек атнага яки 10 көн саенмы җыеп йөрергәме.Бергәләшеп хәл итик.

Игътибарыгыз өчен рәхмәт.